Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлегенең
Югары Акташ авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
карары

2 декабрь 2023 ел                                                                                    № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 2 декабрь 11 сәгать 00 минутта, 2023 елның 2 декабрь 14 сәгать 00 минутта булган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлеге Югары Акташ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 350 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Югары Акташ авылы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 542 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 288 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 288 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлегенең Югары Акташ авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлеге Югары Акташ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 350 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Югары Акташ авылы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Югары Акташ авылы, Совет урамы, 15 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт

муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Акташ авыл җирлеге башлыгы А.В. Шатунов